ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләр раслау хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«2017 елда Россия Федерациясе субъектларының Россия Федерациясе алдындагы бюджет кредитлары буенча йөкләмәләрен (бурычларын) реструктурлаштыру уздыру турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 29 декабрендәге 1718 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турында төзелгән килешүләргә түбәндәге өстәмә килешүләрне расларга:

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы килешүгә 2019 елның 26 апрелендәге 3 номерлы өстәмә килешү, әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә;

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы килешүгә 2019 елның 26 апрелендәге 3 номерлы өстәмә килешү, әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә;

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүгә 2019 елның 26 апрелендәге 3 номерлы өстәмә килешү, әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2019 ел, 15 июль
№ 56-ТРЗ

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы
бюджетына бюджет кредитлары бирү
турындагы килешүләргә
өстәмә килешүләр раслау турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

**Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы килешүгә 3 номерлы өстәмә килешү**

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2014 елның 15 сентябрендәге 288 номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2018 елның 5 июнендәге 712 номерлы боерыгы редакциясендә) нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары Л.В.Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба «Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы күрсәтмәсе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «2017 елда Россия Федерациясе субъектларының Россия Федерациясе алдындагы бюджет кредитлары буенча йөкләмәләрен (бурычларын) реструктурлаштыру уздыру турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1718 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Өстәмә килешүне төзеделәр.

1. Яклар Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы килешүгә (2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы һәм 2018 елның 29 декабрендәге 2 номерлы өстәмә килешүләр редакциясендә) (алга таба – Килешү) түбәндәге үзгәрешләрне кертү турында килештеләр:

а) Килешүнең 6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Әлеге Килешү Яклар тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә һәм Якларның әлеге Килешү буенча, аңа өстәмә килешүләрне дә исәпкә алып, барлык бурычларын тулысынча үтәп бетерүләренә кадәр гамәлдә була.»;

б) Килешүгә 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешүдә (2018 елның 29 декабрендәге 2 номерлы Өстәмә килешү редакциясендә):

4 пунктта:

«г» пунктчасында «шулай ук әлеге пунктның «д» пунктчасы бозылган очракта,» сүзләрен алып ташларга;

түбәндәге эчтәлектәге «и» пунктчасын өстәргә:

«и) күрсәтелгән үзгәрешләр Россия Федерациясе субъекты бюджеты дефицитына китергән очракта Россия Федерациясе субъекты бюджеты турындагы законга тәкъдим ителгән үзгәрешләрне Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте закон чыгару органына керткәнче килештерү өчен Россия Федерациясе Финанслар министрлыгына юлларга.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Заемщик тарафыннан бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычларны һәм (яки) өлешләп түләү процентларын түләү графигы өлешендә Өстәмә килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта, шулай ук бурычлы затның Россия Федерациясе субъекты бюджеты дефицитының чик мәгънәләре һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычы күләме, шулай ук әлеге пунктның дүртенче абзацында каралган, Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъектының чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлары (алга таба - базар алыш-бирешләре буенча бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме) буенча йөкләмәләре бозылуга бәйле рәвештә агымдагы елның 1 июленә кадәрге срокта вакытыннан алда капламавы очрагында,

Заемщик йөкләмәләрне үти башлау срогына Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән төп ставканың 1/300 күләмендә пеня түли, бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычның гомуми күләменнән йөкләмәләр үтәлмәгән һәр көн өчен.

Бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны һәм (яки) өлешләп түләү процентларын түләү графигы белән билгеләнгән түләү көне килеп җиткәннән соң 14 эш көне узганнан соң да Заемщик тарафыннан бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурыч һәм (яки) өлешләп түләү процентлары түләнмәгән очракта, төп бурыч буенча капланмаган реструктуризацияләнгән бурыч һәм кредит буенча процентлар, шулай ук график буенча конкрет датага караган өлешләп түләү процентлары Заемщик тарафыннан вакытыннан алда берьюлы капланырга тиешләр. Бер үк вакытта әлеге чор өчен пенялар да түләнергә тиеш.

Заемщик 2017 елда Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең (алга таба – Кагыйдәләр) 11 пунктындагы «з» пунктчасы нигезләмәләрен бозган очракта, һәм Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «е» пунктчасы нигезләмәләрен бозган очракта, Заемщик Кредитор күрсәтелгән шартларның үтәлмәве турында хәбәр иткән вакыттан алып 60 көн эчендә капланмаган төп бурыч һәм кредитлар буенча процентлар буенча реструктуризацияләнгән бурычны, шулай ук Заемщик тиешле чорда фактта түләгән өлешләп түләү процентлары суммаларын чигереп, өлешләп түләү процентларын вакытыннан алда берьюлы каплый.

Заемщик хисап елы нәтиҗәләре буенча Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «б» - «г» пунктчалары һәм әлеге Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчалары нигезләмәләрен үтәмәгәндә, Заемщик агымдагы финанс елында бурычларны түләү графигы нигезендә бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны һәм өлешләп түләгән өчен процентларны каплый, шулай ук Кредиторның күрсәтелгән шартларның үтәлмәве турында хәбәре нигезендә Россия Федерациясе субъекты бюджет кытлыгының иң чик күрсәткечләреннән арткан күләмдәге һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычы күләмендәге бурычын, шул исәптән базар алыш-бирешләре буенча бурыч йөкләмәләренең гомуми күләмендәге Кагыйдәләр һәм әлеге Өстәмә килешү белән билгеләнгән йөкләмәләрен вакытыннан алда каплый, ләкин агымдагы елның 1 июленә кадәр реструктуризацияләнгән бурычның гомуми күләменең 20 процентыннан да артыгын түгел (алга таба – бурычлы затның иң чик күрсәткечләрне үтәмәү өчен бюджет кредитлары буенча йөкләмәләрен вакытыннан алда каплавы).

Заемщик хисап елы нәтиҗәләре буенча йөкләмәләрен үтәмәгән өчен Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «б», «г» пунктчаларында, шулай ук әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында каралган җаваплылыктан түбәндәге очракларда азат ителә:

бурычлы затның бюджет кредитлары буенча иң чик күрсәткечләрне үтәмәве өчен (1 июльгә кадәр) йөкләмәләрен вакытыннан алда каплавы датасына кадәр

Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) вәкаләтләре туктал һәм аның урынына Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты заты (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) итеп башка зат сайланганда (билгеләнгәндә)

яки Россия Федерациясе Финанслар министрлыгы тарафыннан бурычлы затның бюджет кредитлары буенча иң чик күрсәткечләрне үтәмәве өчен йөкләмәләрен вакытыннан алда каплавын тәэмин итмәвенә бәйле рәвештә мәҗбүр итүнең бюджет чараларын куллану турында карар кабул ителүгә кадәр (Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) (Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) вәкаләтләре срогы дәвамында бер тапкыр кулланыла), әлеге зат әлеге пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән йөкләмәләрне алмаган булса;

әгәр дә йөкләмәләрне үтәмәү бурычлы затның йөкләмәләрне үтәвенә комачау итә торган гадәттән тыш хәлләр (федераль характердагы гадәттән тыш хәлләр) нәтиҗәсендә килеп чыкса.

Заемщикның Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «а», «д» - «ж», «и» һәм «л» пунктчаларын, шулай ук әлеге Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «а», «г», «д», «ж» һәм «и» пунктчаларын үтәмәве Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затының (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесенең) Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органының аның гамәлләре (гамәл кылмаулары) әлеге шартларның бозылуына китергән вазыйфаи затына карата Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылык чараларын куллануына китерә.

Заемщик тарафыннан әлеге пунктның икенче-дүртенче абзацларында күрсәтелгән таләпләр үтәлмәгән очракта Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган чаралар кулланыла.

2. Әлеге Өстәмә килешүнең 1 пунктының «б» пунктчасының өченче абзацының һәм унынчы-унөченче абзацлары нигезләмәләре Якларның Килешүгә 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешү үз көченә кергән көннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге Өстәмә килешүнең 1 пунктының «б» пунктчасының дүртенче һәм бишенче абзацларының, шулай ук җиденче (Россия Федерациясе субъекты бюджеты дефицитының иң чик күрсәткечләре һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычы күләме, шулай ук Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъектының чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлары бозылуга бәйле рәвештә бурычлы затның йөкләмәләрен агымдагы елның 1 июленә кадәрге срокта вакытыннан алда капламавы өлешендә) һәм ундүртенче абзацлары нигезләмәләре Якларның 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

4.Килешүнең аңа каршы килми торган һәм әлеге Өстәмә килешүдә кагылмаган калган шартлары үзгәрми, һәм Яклар алар буенча үзләренең йөкләмәләрен раслыйлар.

5. Әлеге Өстәмә килешү Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора һәм Яклар тарафыннан имзаланган көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге Өстәмә килешү һәр як өчен берәр нөсхә итеп, бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә 5 биттә төзелде.

**Юридик адреслар**

**Кредитор:** Россия Федерациясе Финанс министрлыгы,
Ильинка ур., 9, Мәскәү ш., 109097.

**Заемщик:** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты,
Ирек мәйданы, 1, Казан ш., 420060.

**Якларның имзалары**

| | |
|---|---|
| **Кредитордан:** | **Заемщиктан:** |
| Россия Федерациясе<br>Финанс министрының<br>беренче урынбасары | Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры |
| ________________Л.В. Горнин | ______________А.В. Песошин |
| **М.У.** | **М.У.** |

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы
бюджетына бюджет кредитлары бирү
турындагы килешүләргә
өстәмә килешүләр раслау турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы килешүгә 3 номерлы өстәмә килешү**

Мәскәү ш. 2019 елның 26 апреле

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2014 елның 15 сентябрендәге 288 номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2018 елның 5 июнендәге 712 номерлы боерыгы редакциясендә) нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары Л.В.Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба «Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы күрсәтмәсе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «2017 елда Россия Федерациясе субъектларының Россия Федерациясе алдындагы бюджет кредитлары буенча йөкләмәләрен (бурычларын) реструктурлаштыру уздыру турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1718 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Өстәмә килешүне төзеделәр.

1. Яклар Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы килешүгә (2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы һәм 2018 елның 29 декабрендәге 2 номерлы өстәмә килешүләр редакциясендә) (алга таба – Килешү) түбәндәге үзгәрешләрне кертү турында килештеләр:

а) Килешүнең 6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Әлеге Килешү Яклар тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә һәм Якларның әлеге Килешү буенча, аңа өстәмә килешүләрне дә исәпкә алып, барлык бурычларын тулысынча үтәп бетерүләренә кадәр гамәлдә була.»;

б) Килешүгә 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешүдә (2018 елның 29 декабрендәге 2 номерлы Өстәмә килешү редакциясендә):

4 пунктта:

«г» пунктчасында «шулай ук әлеге пунктның «д» пунктчасы бозылган очракта,» сүзләрен алып ташларга;

түбәндәге эчтәлектәге «и» пуктчасын өстәргә:

«и) күрсәтелгән үзгәрешләр Россия Федерациясе субъекты бюджеты дефицитына китергән очракта Россия Федерациясе субъекты бюджеты турындагы законга тәкъдим ителгән үзгәрешләрне Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте закон чыгару органына керткәнче килештерү өчен Россия Федерациясе Финанслар министрлыгына юлларга.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Заемщик тарафыннан бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычларны һәм (яки) өлешләп түләү процентларын түләү графигы өлешендә Өстәмә килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта, шулай ук бурычлы затның Россия Федерациясе субъекты бюджеты дефицитының чик мәгънәләре һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычы күләме, шулай ук әлеге пунктның дүртенче абзацында каралган, Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъектының чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлары (алга таба - базар алыш-бирешләре буенча бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме) буенча йөкләмәләре бозылуга бәйле рәвештә агымдагы елның 1 июленә кадәрге срокта вакытыннан алда капламавы очрагында,

Заемщик йөкләмәләрне үти башлау срогына Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән төп ставканың 1/300 күләмендә пеня түли, бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычның гомуми күләменнән йөкләмәләр үтәлмәгән һәр көн өчен.

Бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны һәм (яки) өлешләп түләү процентларын түләү графигы белән билгеләнгән түләү көне килеп җиткәннән соң 14 эш көне узганнан соң да Заемщик тарафыннан бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурыч һәм (яки) өлешләп түләү процентлары түләнмәгән очракта, төп бурыч буенча капланмаган реструктуризацияләнгән бурыч һәм кредит буенча процентлар, шулай ук график буенча конкрет датага караган өлешләп түләү процентлары Заемщик тарафыннан вакытыннан алда берьюлы капланырга тиешләр. Бер үк вакытта әлеге чор өчен пенялар да түләнергә тиеш.

Заемщик 2017 елда Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең (алга таба – Кагыйдәләр) 11 пунктындагы «з» пунктчасы нигезләмәләрен бозган очракта, һәм Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «е» пунктчасы нигезләмәләрен бозган очракта, Заемщик Кредитор күрсәтелгән шартларның үтәлмәве турында хәбәр иткән вакыттан алып 60 көн эчендә капланмаган төп бурыч һәм кредитлар буенча процентлар буенча реструктуризацияләнгән бурычны, шулай ук Заемщик тиешле чорда фактта түләгән өлешләп түләү процентлары суммаларын чигереп, өлешләп түләү процентларын вакытыннан алда берьюлы каплый.

Заемщик хисап елы нәтиҗәләре буенча Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «б» - «г» пунктчалары һәм әлеге Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчалары нигезләмәләрен үтәмәгәндә, Заемщик агымдагы финанс елында бурычларны түләү графигы нигезендә бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны һәм өлешләп түләгән өчен процентларны каплый, шулай ук Кредиторның күрсәтелгән шартларның үтәлмәве турында хәбәре нигезендә Россия Федерациясе субъекты бюджет кытлыгының иң чик күрсәткечләреннән арткан күләмдәге һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычы күләмендәге бурычын, шул исәптән базар алыш-бирешләре буенча бурыч йөкләмәләренең гомуми күләмендәге Кагыйдәләр һәм әлеге Өстәмә килешү белән билгеләнгән йөкләмәләрен вакытыннан алда каплый, ләкин агымдагы елның 1 июленә кадәр реструктуризацияләнгән бурычның гомуми күләменең 20 процентыннан да артыгын түгел (алга таба – бурычлы затның иң чик күрсәткечләрне үтәмәү өчен бюджет кредитлары буенча йөкләмәләрен вакытыннан алда каплавы).

Заемщик хисап елы нәтиҗәләре буенча йөкләмәләрен үтәмәгән өчен Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «б», «г» пунктчаларында, шулай ук әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында каралган җаваплылыктан түбәндәге очракларда азат ителә:

бурычлы затның бюджет кредитлары буенча иң чик күрсәткечләрне үтәмәве өчен (1 июльгә кадәр) йөкләмәләрен вакытыннан алда каплавы датасына кадәр
Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) вәкаләтләре тукталу һәм аның урынына Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты заты (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) итеп башка зат сайланганда (билгеләнгәндә)

яки Россия Федерациясе Финанслар министрлыгы тарафыннан бурычлы затның бюджет кредитлары буенча иң чик күрсәткечләрне үтәмәве өчен йөкләмәләрен вакытыннан алда каплавын тәэмин итмәвенә бәйле рәвештә мәҗбүр итүнең бюджет чараларын куллану турында карар кабул ителүгә кадәр (Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) (Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) вәкаләтләре срогы дәвамында бер тапкыр кулланыла), әлеге зат әлеге пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән йөкләмәләрне алмаган булса;

әгәр йөкләмәләрне үтәмәү бурычлы затның йөкләмәләрне үтәвенә комачау итә торган гадәттән тыш хәлләр (федераль характердагы гадәттән тыш хәлләр) нәтиҗәсендә килеп чыкса.

Заемщикның Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «а», «д» - «ж», «и» һәм «л» пунктчаларын, шулай ук әлеге Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «а», «г», «д», «ж» һәм «и» пунктчаларын үтәмәве Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затының (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесенең) Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органының аның гамәлләре (гамәл кылмаулары) әлеге шартларның бозылуына китергән вазыйфаи затына карата Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылык чараларын куллануына китерә.

Заемщик тарафыннан әлеге пунктның икенче-дүртенче абзацларында күрсәтелгән таләпләр үтәлмәгән очракта Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган чаралар кулланыла.

2.Яклар Килешүнең 3.2 пунктының «з» пунктчасында күрсәтелгән йөкләмәләр әлеге Өстәмә килешү имзаланган көннән Заемщик тарафыннан Килешүгә 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешүнең 4 пунктының «и» пунктчасы нигезендә әлеге Өстәмә килешү редакциясендә үтәлергә тиешле дип килештеләр.

3. Әлеге Өстәмә килешүнең 1 пунктының «б» пунктчасының өченче абзацының һәм унынчы-унөченче абзацлары нигезләмәләре Якларның Килешүгә 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешү үз көченә кергән көннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

4.Әлеге Өстәмә килешүнең 1 пунктының «б» пунктчасының дүртенче һәм бишенче абзацларының, шулай ук җиденче (Россия Федерациясе субъекты бюджеты дефицитының иң чик күрсәткечләре һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычы күләме, шулай ук Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъектының чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлары бозылуга бәйле рәвештә бурычлы затның йөкләмәләрен агымдагы елның 1 июленә кадәрге срокта вакытыннан алда капламавы өлешендә) һәм үндүртенче абзацлары нигезләмәләре Якларның 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

5.Килешүнең аңа каршы килми торган һәм әлеге Өстәмә килешүдә кагылмаган калган шартлары үзгәрми, һәм Яклар алар буенча үзләренең йөкләмәләрен раслыйлар.

6. Әлеге Өстәмә килешү Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора һәм Яклар тарафыннан имзаланган көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге Өстәмә килешү һәр як өчен берәр нөсхә итеп, бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә 5 биттә төзелде.

**Юридик адреслар**

**Кредитор:** Россия Федерациясе Финанс министрлыгы,
Ильинка ур., 9, Мәскәү ш., 109097.

**Заемщик:** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты,
Ирек мәйданы, 1, Казан ш., 420060.

**Якларның имзалары**

| **Кредитордан:** | **Заемщиктан:** |
|---|---|
| Россия Федерациясе<br>Финанс министрының<br>беренче урынбасары | Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры |
| ________________Л.В. Горнин | ________________А.В. Песошин |
| **М.У.** | **М.У.** |

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы
бюджетына бюджет кредитлары бирү
турындагы килешүләргә
өстәмә килешүләр раслау турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүгә 3 номерлы өстәмә килешү**

Мәскәү ш. 2019 елның 26 апреле

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2014 елның 15 сентябрендәге 288 номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2018 елның 5 июнендәге 712 номерлы боерыгы редакциясендә) нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары Л.В.Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба «Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы күрсәтмәсе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «2017 елда Россия Федерациясе субъектларының Россия Федерациясе алдындагы бюджет кредитлары буенча йөкләмәләрен (бурычларын) реструктурлаштыру уздыру турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1718 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Өстәмә килешүне төзеделәр.

4. Яклар Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүгә (2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы һәм 2018 елның 29 декабрендәге 2 номерлы өстәмә килешүләр редакциясендә) (алга таба – Килешү) түбәндәге үзгәрешләрне кертү турында килештеләр:

а) Килешүнең 6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Әлеге Килешү Яклар тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә һәм Якларның әлеге Килешү буенча, аңа өстәмә килешүләрне дә исәпкә алып, барлык бурычларын тулысынча үтәп бетерүләренә кадәр гамәлдә була.»;

б) Килешүгә 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешүдә (2018 елның 29 декабрендәге 2 номерлы Өстәмә килешү редакциясендә):

4 пунктта:

«г» пунктчасында «шулай ук әлеге пунктның «д» пунктчасы бозылган очракта,» сүзләрен алып ташларга;

түбәндәге эчтәлектәге «и» путктчасын өстәргә:

«и) күрсәтелгән үзгәрешләр Россия Федерациясе субъекты бюджеты дефицитына китергән очракта Россия Федерациясе субъекты бюджеты турындагы законга тәкъдим ителгән үзгәрешләрне Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте закон чыгару органына керткәнче килештерү өчен Россия Федерациясе Финанслар министрлыгына юлларга.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Заемщик тарафыннан бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычларны һәм (яки) өлешләп түләү процентларын түләү графигы өлешендә Өстәмә килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта, шулай ук бурычлы затның Россия Федерациясе субъекты бюджеты дефицитының чик мәгънәләре һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычы күләме, шулай ук әлеге пунктның дүртенче абзацында каралган, Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъектының чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлары (алга таба - базар алыш-бирешләре буенча бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме) буенча йөкләмәләре бозылуга бәйле рәвештә агымдагы елның 1 июленә кадәрге срокта вакытыннан алда капламавы очрагында,

Заемщик йөкләмәләрне үти башлау срогына Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән төп ставканың 1/300 күләмендә пеня түли, бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычның гомуми күләменнән йөкләмәләр үтәлмәгән һәр көн өчен.

Бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны һәм (яки) өлешләп түләү процентларын түләү графигы белән билгеләнгән түләү көне килеп җиткәннән соң 14 эш көне узганнан соң да Заемщик тарафыннан бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурыч һәм (яки) өлешләп түләү процентлары түләнмәгән очракта, төп бурыч буенча капланмаган реструктуризацияләнгән бурыч һәм кредит буенча процентлар, шулай ук график буенча конкрет датага караган өлешләп түләү процентлары Заемщик тарафыннан вакытыннан алда берьюлы капланырга тиешләр. Бер үк вакытта әлеге чор өчен пенялар да түләнергә тиеш.

Заемщик 2017 елда Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең (алга таба – Кагыйдәләр) 11 пунктындагы «з» пунктчасы нигезләмәләрен бозган очракта, һәм Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «е» пунктчасы нигезләмәләрен бозган очракта, Заемщик Кредитор күрсәтелгән шартларның үтәлмәве турында хәбәр иткән вакыттан алып 60 көн эчендә капланмаган төп бурыч һәм кредитлар буенча процентлар буенча реструктуризацияләнгән бурычны, шулай ук Заемщик тиешле чорда фактта түләгән өлешләп түләү процентлары суммаларын чигереп, өлешләп түләү процентларын вакытыннан алда берьюлы каплый.

Заемщик хисап елы нәтиҗәләре буенча Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «б» - «г» пунктчалары һәм әлеге Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчалары нигезләмәләрен үтәмәгәндә, Заемщик агымдагы финанс елында бурычларны түләү графигы нигезендә бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны һәм өлешләп түләгән өчен процентларны каплый, шулай ук Кредиторның күрсәтелгән шартларның үтәлмәве турында хәбәре нигезендә Россия Федерациясе субъекты бюджет кытлыгының иң чик күрсәткечләреннән арткан күләмдәге һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычы күләмендәге бурычын, шул исәптән базар алыш-бирешләре буенча бурыч йөкләмәләренең гомуми күләмендәге Кагыйдәләр һәм әлеге Өстәмә килешү белән билгеләнгән йөкләмәләрен вакытыннан алда каплый, ләкин агымдагы елның 1 июленә кадәр реструктуризацияләнгән бурычның гомуми күләменең 20 процентыннан да артыгын түгел (алга таба – бурычлы затның иң чик күрсәткечләрне үтәмәү өчен бюджет кредитлары буенча йөкләмәләрен вакытыннан алда каплавы).

Заемщик хисап елы нәтиҗәләре буенча йөкләмәләрен үтәмәгән өчен Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «б», «г» пунктчаларында, шулай ук әлеге Өстәмә килешүнең 4 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында каралган җаваплылыктан түбәндәге очракларда азат ителә:

бурычлы затның бюджет кредитлары буенча иң чик күрсәткечләрне үтәмәве өчен (1 июльгә кадәр) йөкләмәләрен вакытыннан алда каплавы датасына кадәр

Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) вәкаләтләре тукталу һәм аның урынына Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты заты (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) итеп башка зат сайланганда (билгеләнгәндә)

яки Россия Федерациясе Финанслар министрлыгы тарафыннан бурычлы затның бюджет кредитлары буенча иң чик күрсәткечләрне үтәмәве өчен йөкләмәләрен вакытыннан алда каплавын тәэмин итмәвенә бәйле рәвештә мәҗбүр итүнең бюджет чараларын куллану турында карар кабул ителүгә кадәр (Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) (Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) вәкаләтләре срогы дәвамында бер тапкыр кулланыла), әлеге зат әлеге пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән йөкләмәләрне алмаган булса;

әгәр дә йөкләмәләрне үтәмәү бурычлы затның йөкләмәләрне үтәвенә комачау итә торган гадәттән тыш хәлләр (федераль характердагы гадәттән тыш хәлләр) нәтиҗәсендә килеп чыкса.

Заемщикның Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «а», «д» - «ж», «и» һәм «л» пунктчаларын, шулай ук әлеге Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «а», «г», «д», «ж» һәм «и» пунктчаларын үтәмәве Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затының (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесенең) Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органының аның гамәлләре (гамәл кылмаулары) әлеге шартларның бозылуына китергән вазыйфаи затына карата Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылык чараларын куллануына китерә.

Заемщик тарафыннан әлеге пунктның икенче-дүртенче абзацларында күрсәтелгән таләпләр үтәлмәгән очракта Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган чаралар кулланыла.

2. Әлеге Өстәмә килешүнең 1 пунктының «б» пунктчасының өченче абзацының һәм унынчы-унөченче абзацлары нигезләмәләре Якларның Килешүгә 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешү үз көченә кергән көннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3.Әлеге Өстәмә килешүнең 1 пунктының «б» пунктчасының дүртенче һәм бишенче абзацларының, шулай ук җиденче (Россия Федерациясе субъекты бюджеты дефицитының иң чик күрсәткечләре һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычы күләме, шулай ук Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъектының чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлары бозылуга бәйле рәвештә бурычлы затның йөкләмәләрен агымдагы елның 1 июленә кадәрге срокта вакытыннан алда капламавы өлешендә) һәм ундүртенче абзацлары нигезләмәләре Якларның 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

4.Килешүнең аңа каршы килми торган һәм әлеге Өстәмә килешүдә кагылмаган калган шартлары үзгәрми, һәм Яклар алар буенча үзләренең йөкләмәләрен раслыйлар.

5. Әлеге Өстәмә килешү Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора һәм Яклар тарафыннан имзаланган көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге Өстәмә килешү һәр як өчен берәр нөсхә итеп, бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә 5 биттә төзелде.

**Юридик адреслар**

**Кредитор:** Россия Федерациясе Финанс министрлыгы,
Ильинка ур., 9, Мәскәү ш., 109097.

**Заемщик:** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты,
Ирек мәйданы, 1, Казан ш., 420060.

**Якларның имзалары**

| **Кредитордан:** | **Заемщиктан:** |
|---|---|
| Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары | Татарстан Республикасы Премьер-министры |
| __________________Л.В. Горнин | ________________А.В. Песошин |
| **М.У.** | **М.У.** |